РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№818-п

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы территориясендә
җәмәгать транспортында йөргән өчен
бер мәртәбә акчалата түләү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Халыкара өлкәннәр көненә багышланган өлкәннәр Декадасы уңаеннан, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 74 һәм 74.1 статьяларына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр түләнә торган акчалата ярдәм чараларын: 1961 елгы һәм аннан өлкәнрәк ир-атларга, 1966 елгы һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшәүче өлкәннәргә, агымдагы елның 15 октябреннән 15 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә күрсәтелгән җайга салына торган тарифлар буенча муниципаль маршрут буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы җәмәгать транспорты оешмалары тарафыннан гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында муниципаль маршрутлар буенча җайга салынулы маршрутлар буенча гамәлгә ашырыла торган автомобиль юлларында йөрү чыгымнарының 100 проценты күләмендә түләүне билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүгә пенсионерларга бер мәртәбә акчалата түләү бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарда күрсәтелгән өстәмә социаль ярдәм чаралары бирү өчен җирле бюджет акчаларыннан финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкче урынбасары - Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты апараты Җитәкчесе М.Р.Кәримов

Татарстан Республикасы

Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
________________ №
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүгә пенсионерларга акчалата түләү биру тәртибе турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе гражданнары, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшәүче 1961 елда туган һәм аннан өлкәнрәк ир - атларга, 1966 елда туган һәм аннан өлкәнрәк хатын-кызларга, агымдагы елның 15 октябреннән 15 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә күрсәтелгән җайга салына торган тарифлар буенча муниципаль маршрут буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы җәмәгать транспорты оешмалары тарафыннан гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында муниципаль маршрутлар буенча җайга салынулы маршрутлар буенча гамәлгә ашырыла торган юл йөрү өчен түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирү механизмын һәм тәртибен билгели (алга таба текст буенча-Нигезләмә).

2. Бер тапкыр акчалата түләү Россия Федерациясе гражданнары, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында яшәүче 1961 елда туган һәм аннан өлкәнрәк ир - атларга, 1966 елда туган һәм аннан өлкәнрәк хатын-кызларга, агымдагы елның 15 октябреннән 15 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә күрсәтелгән җайга салына торган тарифлар буенча муниципаль маршрут буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы җәмәгать транспорты оешмалары тарафыннан гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында муниципаль маршрутлар буенча җайга салынулы маршрутлар буенча гамәлгә ашырыла торган юл йөрү өчен түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә бирелә.

Акчалата түләү бирү турындагы карар Саба муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә (алга таба - Башкарма комитет).

Акчалата түләү бирүне тикшереп тору Саба муниципаль районының Контроль-хисап палатасы һәм Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Акчалата түләү алу өчен гражданнар агымдагы елның ноябрь ае дәвамында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык секторына тубәндәгеләрне тапшыралар:

а) акчалата түләү турында гариза (алга таба - гариза) (1 нче кушымта);

б) җәмәгать транспортында йөргән өчен түләү чыгымнарын раслаучы документлар (билетлар);

в) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (2 нче кушымта);

г) паспорт күчермәсе (2,3 нче битләр, 5 нче бит һәм алга таба тутырганда яшәү урыны буенча теркәлү турындагы мәгълүмат)

д) айлык акчалата түләүне билгеләү өчен гариза әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданның ышанычлы заты тарафыннан тапшырылган очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамәнең (алга таба — ышанычнамә) күчермәсен;

б)айлык түләүне күчерү максатларында гражданга банкта яисә башка кредит

оешмасында ачылган шәхси счет реквизитлары.

Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән, тапшырылган документлар һәм әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән белешмәләр нигезендә, Башкарма комитет, эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә, барлык кирәкле документлар белән акчалата түләү бирү турында гариза теркәлгән көннән башлап, акчалата түләү тапшыру турында яисә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә. Акчалата түләү бирүдән баш тарту очрагында, мөрәҗәгать итүчегә түләүне бирү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (язма рәвештә почта аркылы, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша телефонга хәбәр итеп) мөрәҗәгать итүчегә тиешле карарны җиткерә.

6. Акчалата түләү бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;

әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән акчалата түләү бирү шартларына туры килмәү;

Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнарга акчалата түләү барлык кирәкле документлар белән акчалата түләү бирү турында гариза бирелгән көннән алып 40 эш көне дәвамында кредит оешмаларында ачылган мөрәҗәгать итүчеләрнең шәхси счетларына түләнә.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүгә пенсионерларга акчалата түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетына

**ГАРИЗА**

__________ 20__ ел.

Мин ____________________________________________________________,
мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)

| Шәхесне таныклый торган документның исеме | Серия һәм номер | Кем тарафыннан бирелгән | Бирү датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

түбәндәге адрес буенча теркәлгән:

(теркәлү урыны буенча мөрәҗәгать итүченең адресы, индексы, телефоны, адресы күрсәтелгән электрон почта, шулай ук яшәү урынында теркәлү датасы)

Шәхси счет иминият номеры (СНИЛС) (мөрәҗәгать итүченең)

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә җәмәгать транспортында йөргән өчен бер тапкыр акчалата түләү турында” Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының ________________________________ карары нигезендә акчалата түләүне, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә күрсәтелгән җәмәгать транспорты хезмәтләренә фактта тотылган чыгымнар күләмендә бирүләрен сорыйм

Акчалата түләүне үзем тәкъдим иткән реквизитлар буенча күчерүегезне сорыйм.

Социаль ярдәм чараларын күрсәтүдән баш тартуга мәгълүмат алуга риза

(почта адресы буенча, электрон документ формасында электрон почта, телефонга СМС-хәбәр белән)

Дата____________ ______________________________________
(гариза бирүче имзасы)

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы территориясендә
җәмәгать транспорты хезмәтләре
күрсәтүгә пенсионерларга акчалата
түләү бирү тәртибе турындагы
нигезләмәгә
2 нче кушымта

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин,________________________________________________________

Ф.И.Аи, соңгысы - булган очракта тулысынча)

элемтә мәгълүматы: телефон номеры, электрон почта адресы яисә шәхси мәгълүматлар субъектының почта адресы);

Акчалата түләү бирү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетына, Саба мунииципаль раойнының Конторль-хисап палатасына, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына автоматлаштыру чараларын кулланып яисә мондый чараларны кулланмыйча, җыю, язып алуны, системалаштыруны, туплауны, саклауны да кертеп, башкарыла торган теләсә нинди гамәлне (операцияне) яисә гамәлләр (операцияләр) җыелмасын эшкәртүгә (минем шәхси мәгълүматларымны (белешмәләремне) һәм балигъ булмаган балаларымның шәхси мәгълүматларын (белешмәләрен) төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), алу, куллану, тапшыру (тарату, бирү, керү), шәхессезләндерү, блоклау, бетерү, юк итү) өчен ризалык бирәм.

(Ф.И.Аи. (соңгысы - булган очракта), туу датасы)

фамилиясен, исемен, атасының исемен; туу датасын; гаилә хәлен; паспорт мәгълүматларын; теркәү һәм яшәү урыны адресын; контактлы телефон номерын; банк счеты реквизитларын.

Шәхси мәгълүматларны, балигъ булмаган балалар турында белешмәләрне эшкәртүгә чын ризалык, социаль ярдәм чараларын күрсәтү өчен документларны саклау өчен архив законнарында билгеләнгән срок узганчыга кадәр гамәлдә була.

(дата) (фамилиясе, исеме, атасының исеме) (соңгысы - булган очракта) (имзасы)